ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2025 г. Казань № 664-3/нпс-2025

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2026 елга Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләренә иң чик максималь бәяне билгеләү турында» 22.10.2025 ел, №249-1/нпс-2025 карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 18.12.2025 ел, №34-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2026 елга Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләренә иң чик максималь бәяне билгеләү турында» 22.10.2025 ел, №249-1/нпс-2025 карарына үзгәреш кертеп, 1 пунктында «12 719» саннарын «12 931» саннары белән алмаштырырга.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов